**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТОЙГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ТОЙГУҖА АВЫЛЫ**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ**

---

КАРАР

«06» апрель 2024 ел № 2

2024 елда Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Тойгуҗа авыл җирлеге Тойгуҗа
торак пунктында гражданнарның
үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Тойгуҗа авыл җирлеге Тойгуҗа авылы гражданнары җыены

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

2.1. Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Тойгуҗа авылына 1 (бер данә су насосы сатып алу););

2.2. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (суүткәргеч задвижка һәм янгын гидрантларын комплектта сатып алу; Тойгуҗа авылында суүткәргеч задвижка һәм янгын гидрантларын урнаштыру).

2.3. Торак пункт территориясен төзекләндерү: (Тойгуҗа авыл җирлеге территориясендә үлән чабу).

2.4. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Тойгуҗа авылында Үзәк, Яшьләр, Мәктәп Тыкрыгы урамнары буенча юлларны кардан чистарту)»

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, 10 көн эчендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында. www mendsleevsk.tatarstan.ru “Тойгуҗа авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Тойгуҗа авыл җирлеге башлыгы ____________ Р.А. Сафин
(имза) (имзаның аңлатмасы)